ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

02.12.2024 — с. Коргуза — 39

Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең
Егидерево авылында халыктан үзара салым җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Уставы нигезендә, Карагуҗа авыл җирлегенең 2024 елның 22 ноябрендәге гражданнар җыенында кабул ителгән 01 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты

карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Егидерево авылында үзара салым акчасын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы — Д.В.Плохов

Карагуҗа авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2024 елның 2
декабреннән
№ 39 карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авылы җирлегенең Егидерево авылында халыктан үзара салым җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Егидерево авылында үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчасын түләү 2025 елның 1нче гыйнварыннан 2025 елның 1нче мартына кадәр гражданнар җыенында катнашуларына бәйсез рәвештә Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Егидерево авлы территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары

б) контрактчылар

в) ашыгыч хезмәт солдатлары.

Аерым категория гражданнар өчен:

а) Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар

б) 1 төркем инвалидлар,

в) уку йортлары студентлары

г) күпбалалы гаиләләр

түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

4. Бер мәртәбә бирелә торган түләү турында хәбәрнамә (хәбәр итү) бланкы почта элемтәсе аша юллама бирү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почтадан акча күчерү белән (исәп-хисап оешмалары) тормышка ашыруга яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр https://uslugi.tatarstan.ru/ порталы ссылкасы аша башкарыла.

7. Түләү фактын раслау - приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Карагуҗа авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2024 елның 2 декабреннән
№ 39 карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________

Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү турында

Түләүченең Ф. И.А.и.
_______________________________________________________________________
Адрес: _____________________________________________________________
_____________________________________________________________ нигезендә
Сезгә ________________________ вакытына кадәр
_____________________________________________________ чараларны тормышка ашыру өчен ______________ сум күләмендә,
түбәндәге реквизитлар буенча:
____________________________________________________ бер тапкыр акча түләргә кирәк.
Алучының банк БИК _______________________________________
Сч. № ___________________________________
Алучының сч. №__ . __________________________________________
ИНН ____________________________________________
КПП ____________________________________________
КБК ________________ ОКАТО___________________
Түләүне билгеләү
_________________________________________________________________

Җитәкче __________________ ________________________________________
М. у. (имза) (имзаны киңәйтеп язу)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № __________________
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында _______________________
(муниципаль берәмлек исеме)
_________________ сум күләмендә.
Түләүченең Ф. И.А.и. _________________________________________________
Адрес:
_______________________________________________________________________
Алдым «__» __________________ 20___ ел. _______________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Әгәр дә хәбәр түләүчегә шәхсән бирелсә, аермалы төпсәсе тутырыла һәм ________________ авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*